| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>БОЛЬШЕТИГАНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

Зур Тигәнәле авылы

21.10.2019 № 133

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы карар проекты турында**

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясы, «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 21.07.2005 ел, № 97-ФЗ Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 ел, № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә,

**Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы карар проектын хупларга (Кушымта № 1).

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы карарына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу һәм гражданнарның аның турында фикер алышуларда катнашуы тәртибен расларга ( Кушымта № 2).

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына

үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында”гы карары проекты буенча ачык тыңлаулар үткәрергә.

3.Түбәндәгеләрне билгеләргә :

3.1. Халык тыңлауларын үткәрү датасы - 5.11.2019.

3.2.Халык тыңлауларын үткәрү вакыты-13.00 сәгать.

3.3.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл мәдәният йорты бинасын гавами тыңлаулар уздыру урыны итеп билгеләргә, адресы: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, 17 нче йорт.

4.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталындагы җирлек сайтында урнаштырырга һәм махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

5.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы аппаратына һәм Башкарма Комитетына халык алдында тыңлаулар уздыруны, күрсәтелгән карар проекты буенча гражданнар тәкъдимнәрен кабул итүне һәм исәпкә алуны тәэмин итәргә.

6.Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге комитеты җирле үзидарә органнарына халык алдында тыңлауларда әйтелгән һәм фикер алышу барышында кергән тәкъдимнәрне исәпкә алып, карар проектын эшләп бетерергә һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы сессиясенә карауга кертергә.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

8. Әлеге карар, әгәр федераль законда башкасы каралмаган булса, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 44 статьясындагы 8 өлеше нигезендә үз көченә керә.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.Җ.Әхмәтҗанов**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының
2019 елның 21 октябреннән 133 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү**

**1. 6 нчы статьяда:**

**а)** 1 нче пунктта:

17 нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бирергә:

“17) җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге һәм аларга юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү, шул исәптән парковкаларны (парковка урыннарын) булдыру һәм аларның эшләвен тәэмин итү, җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, юл хәрәкәтен оештыру, шулай ук автомобиль юлларын куллану һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өлкәсендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.»;

- түбәндәге эчтәлекле 20 нче пунктча өстәргә:

«20) Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, үзирекле корылманы сүтү яки аны авыл җирлеге торак пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында Карар кабул итү.».

**2. 7 нче статьяда:**

а) 1 пунктта 13 пунктчада «күзәтүчесез яшәүче хайваннарны тоту һәм карап тору чаралары» сүзләрен «хуҗасыз яшәүче хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлек" сүзләренә алмаштырырга.

**3. 23 нче статьяда:**

**а)** 3 пунктта 6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"6) җирлекара территориядә урнашкан торак пунктта, яңа оешкан җирлек булдыру турында халык инициативасын тәкъдим итү максатларында, шулай ук яңа оешкан җирлектә, әгәр сайлау хокукына ия кешеләр саны 300 дән артмаган булса, яңа төзелгән җирлекнең җирле үзидарә органнары структурасын билгеләү мәсьәләсе буенча;”;

**б)** 7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

"Гражданнар җыены - тулы хокуклы санала, әгәр дә торак пункт яки җирлектә сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы катнашса. Торак пунктта , әлеге торак пунктта сайлау хокукына ия кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены гражданнар җыенын үткәрү турында карар кабул ителгән

көннән бер айдан да соңга калмыйча этаплап уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар, киләсе этапларда тавыш бирүдә катнашмый. Җыенда катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, гражданнар җыены карары кабул ителгән дип санала.

**4. 31нче статьяда:**

**а)** 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлек Советы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, вазыйфаларны башкарырга тиеш. Җирле үзидарәнең сайланулы органы депутаты, әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законы, “Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законы, «Аерым категория затларга аерым категория затларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль законы, "Аерым категория затларга исәп-хисап ачу, әгәр әлеге Федераль законда башкасы каралмаган булса, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында акчалата һәм кыйммәтләрне саклау, чит ил финанс инструментларын биләү һәм (яки) куллануны тыю турында» законда каралган чикләүләрне, тыюларны үтәмәсә, вазыйфаларын тиешле башкармаса вәкаләтләре алдан бетә.»;

**б)** 4 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«2) Җирлек Советы депутаты, муниципаль вазыйфа биләгән муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнарының вазыйфаи затлары тарафыннан беренче чиратта кабул ителергә хокуклы»;

**в)** 6 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- үзе яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерцияле оешма белән идарә итүдә яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга ("Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре советы" Ассоциациясе идарәсендә, муниципаль берәмлекләрнең билгеләнгән тәртиптә теркәлгән башка берләшмәләре, сәяси партияләр, профсоюз белән идарә итүдә катнашудан тыш, башка иҗтимагый оешманың съездында (конференциясендә) яки гомуми җыелышы, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәте идарәсендә катнашудан тыш), Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте акты нигезендә оешманың коллегиаль органы эшчәнлегендә түләүсез катнашудан тыш, оешманың идарә итү органнарында һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итү (гамәлгә куючы (акционер) муниципаль берәмлек, муниципаль берәмлек исеменнән муниципаль милектә булган акцияләрне (устав капиталында катнашу өлешләрендә) гамәлгә куючы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен

билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә, федераль законнарда каралган башка очраклар";

**г)** 7 пунктта 3 абзацта “җирлек Советына" сүзләреннән соң "яисә күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чараларын куллану" сүзләрен өстәргә».

**5. 34 нче статьяда:**

**а)** 1 пунктта 23 пунктчаны үз көчен югалткан дип танырга.

**6. 49 нчы статьяда:**

**а)** 1нче пунктта:

- 3 пунктчада 2 абзацта сүзләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

« - Россия Федерациясе граждан законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы сүтү, үзирекле корылманы сүтү яки аны авыл җирлеге торак пунктларында билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карар кабул итә.»;

- 4 пунктчада 3 абзацта «торак урыннар» сүзләрен «күпфатирлы йорттагы урыннар» сүзләренә алмаштырырга;

- 8 пунктчада 15 абзацта "күзәтүчесез яшәүче хайваннарны тоту һәм карап тору буенча чаралар”сүзләрен “хуҗасыз яшәүче хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлек” сүзләренә алмаштырырга.

**7. 71 нче статьяда:**

**а)** 1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“Авыл җирлегендә халык саны арту яки кимү сәбәпле, авыл җирлеге Советы депутатлары санын арттыручы яки киметүче үзгәрешләр күрсәтелгән , үзгәрешләр кертү турында мондый муниципаль норматив хокукый актны кабул иткән авыл җирлеге Советының вәкаләтләре срогы чыккач үз көченә керә”.

**б)** 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Халыкка таратылырга тиешле мәгълүматны үз эченә алган муниципаль актлар халыкка хәбәр ителергә тиеш. Муниципаль актны халыкка җиткерү «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә районның рәсми сайтында акт текстын урнаштыру юлы белән яисә җирлек халкына хокукый акт текстын үзәкләштерелгән тәртиптә җибәрү (тарату) юлы белән, шул исәптән махсус басма рәвешендә, яисә җирлекнең торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында хокукый акт текстын урнаштыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Күрсәтелгән стендларның саны һәм аларның урнашу урыннары авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана һәм халыкның муниципаль хокукый акты тексты белән тоткарлыксыз танышу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш.

Кеше һәм граждан хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы, гамәлгә куючысы муниципаль берәмлек булган оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Муниципаль хокукый актны яисә җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару дип аның тулы текстын тиешле муниципаль берәмлектә таратыла торган вакытлы матбугатта беренче

бастырып чыгару санала. Хокукый акт текстын бастырып чыгарганда башка массакүләм мәгълүмат чараларында әлеге басманың рәсми булып торуы турындагы билге булырга тиеш.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәр басмасын кулланырга хокуклы. Муниципаль хокукый актның тулы тексты рәсми челтәр басмасында басылып чыккан очракта (урнаштырылган), аның күләмле график һәм таблица кушымталары басма матбугатта китерелмәскә мөмкин.

Шулай ук хокукый акт текстын яки хокукый акт проектын «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында" «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә һәм районның массакүләм мәгълүмат чараларын челтәр бастырып чыгаруда рәсми бастырып чыгару булып тора.

Татарстан Республикасы «Алексеевск муниципаль районының Зур Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын һәм аңа үзгәрешләр кертү турында муниципаль актларны рәсми бастырып чыгару чыганагы сыйфатында шулай ук хокукый акт текстын Россия Федерациясе Юстиция министрлыгы порталындагы «Россия Федерациясендә норматив хокукый актлар» бүлегендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру кулланыла.

Норматив-хокукый актлар Татарстан Республикасының 2 дәүләт телендә бастырылырга тиеш.

Федераль закон белән таралуы чикләнгән белешмәләр булган муниципаль хокукый актларны бастырып чыгару (халыкка җиткерү) рөхсәт ителми.»;

**в)** 9 пунктны үз көчен югалткан дип санарга.

**8. 85 нче статьяда:**

**а)** 1 пунктта «Россия Федерациясе Бюджет законнары һәм башка норматив» сүзләрен «нигезләмәләр» сүзенә алмаштырырга, «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга башка түләүләр буенча гавами норматив йөкләмәләр һәм йөкләмәләрне, шулай ук дәүләт (муниципаль) контрактлар, килешүләр шартларын үтәүне аңлата торган хокукый актлар" сүзләрен өстәргә;»;

**б)** 2 пунктта «бюджет хокук мөнәсәбәтләре өлкәсендә» сүзләрен төшереп калдырырга.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.Җ.Әхмәтҗанов**

СОВЕТ БОЛЬШЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советының
2019 елның 21 октябреннән 133 номерлы
карарына 2 нче кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ “ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЗУР ТИГӘНӘЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫНА ҮЗГӘРЕШЛӘР ҺӘМ ӨСТӘМӘЛӘР КЕРТҮ ТУРЫНДАГЫ” КАРАР ПРОЕКТЫ БУЕНЧА ФИКЕР АЛЫШУДА ГРАЖДАННАРНЫҢ КАТНАШУЫ, ҺӘМ КАРАР ПРОЕКТЫНА ГРАЖДАННАРНЫҢ ТӘКЪДИМНӘРЕН ИСӘПКӘ АЛУ ТӘРТИБЕ**

1. «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проектына тәкъдимнәр Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге Советы аппаратына түбәндәге адрес буенча язма рәвештә кертелә: Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, 17 нче йорт.

Тәкъдимнәр «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зур Тигәнәле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» карар проекты тексты “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырылган көннән алып 8 сәгатьтән 16 сәгатькә кадәр кабул ителә.

2. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашу өчен гаризалар Татарстан Республикасы, Алексеевск районы, Зур Тигәнәле авылы, 17 нче йорт адресы буенча, шәхсән яисә почта аша (конвертында “Устав буенча фикер алышу» тамгасы белән) бирелә.

**Алексеевск муниципаль районы**
**Зур Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы,**
**Совет Рәисе** **С.Җ.Әхмәтҗанов**